ГЛАВА СРЕДНЕКИРМЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Ленина, д.16А, с. Средние Кирмени, Мамадышский район, Республика Татарстан, 422171

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УРТА КИРМӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Ленин ур., 16А нчы йорт, Урта Кирмән авылы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422171

тел.(факс): (85563) 2-92-38;2-92-44 e-mail: Skimer.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Постановление — Карар

№ 1 — 20 нче февраль 2023 ел

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге Башлыгының 2012 елның 1 августындагы 4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Мамадыш районы прокурорының2023нче елның 31 мартындагы 02-08-02-2023 номерлы протесты,"Дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны тәэмин итү хакында" 2009 елның 09 февралендәге 8-ФЗ номерлы, "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында"2003 елның 6 ноябрендәге 131-ФЗ номерлы, 2022 елның 14 июлендәге N 270-ФЗ федераль законнар, Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге Уставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге Башлыгынын 2012 елның 1 августындагы "Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге җирлеүзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалануны оештыру тәртибе турында" Нигезләмәне раслау хакында" 4 нче номерлы карарына (алгатаба-Карар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 Әлеге Карарга Кушымтаның 8.12 пунктында “Интернет челтәрендә” сүзләрен “рәсми сайтларда” сүзләренә алмаштырырга;

1.2 Әлеге КарарграКушымтаның 9.6 пунктында "җирле үзидарә органнарының" сүзләрен “җирле үзидарә органнарының һәм ведомство буйсынуындагы оешмаларның" сүзләренә алмаштырырга, “хезмәткәрләр"сүзләреннән соң “ведомство карамагындагы оешмаларның хезмәткәрләре” сүзләрен өстәргә;

1.3 Әлеге КарарграКушымтаның 6 пунктындагы 4 пунктчасында “җирле үзидарә органнары” сүзләреннән соң “һәмведомство буйсынуындагы оешмалар” сүзләрен өстәргә;

1.4 Әлеге КараргаКушымтаның3.1 пунктына “һәм ведомство буйсынуындагы оешмалар” сүзләрен өстәргә;

1.5 Әлеге КараргаКушымтаның 5.1 пунктындагы 4 пунктчасында "җирле үзидарә органнарының, аларның вазифаи затларының" сүзләрен “җирле үзидарә органнарының һәм ведомство буйсынуындагы оешмаларның, әлеге органнарның һәм оешмаларның вазифаи затларының" сүзләренә алмаштырырга;

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсмисайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының (pravo.tatarstan.ru) рәсми порталында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге караның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгыма алам.

Урта Кирмән авыл җирлеге башлыгы Б.Ф.Хасанов